КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 235 нче; 2016 ел, 13 май, 302 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 757 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан М.А.Җәббаровны, Ю.А.Кннины чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Земсков Олег Владимировичны – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасарын;

Җәләлова Алсу Назыйр кызын - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Стандартлар контроле һәм медицина эшчәнлеге сыйфаты идарәсенең медицина белеме һәм аттестация бүлеге башлыгын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин